БАЛТАСИНСКИЙ РАЙОННЫЙ
ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАЛТАЧ РАЙОН
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

«29» 01 2026 ел № 51

Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы яшьләр сәясәте дәүләт оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2018 елның 14 августындагы 665 номерлы карарын (22.09.2025 ред.) үтәү йөзеннән, Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты карар бирә:

1. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләү шартлары турындагы Нигезләмәне расларга.

2. Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең һәм белгечләренең, җитәкчеләрнең гомумтармак вазыйфаларының, сәнгать һәм кинематография, мәдәният хезмәткәрләренең, эшчеләрнең гомумтармак һөнәри квалификация төркемнәре хезмәткәрләренең хезмәтенә түләү шартлары турындагы Нигезләмәне расларга.

3. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» 2025 елның 6 мартындагы 106 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

4. Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт өчен түләү шартлары турында» Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитетының 2025 елның 6 мартындагы 106 номерлы карарына үзгәрешләр кертү хакында» 2025 елның 24 маендагы 164 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.

5. Әлеге карарның 1 пункты нигезендә билгеләнә торган Балтач муниципаль районының яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренең хезмәт хакы, хезмәткәрләрнең вазыйфаи бурычлары күләмен саклап калу һәм шул ук квалификациядәге эшләрне башкару шарты

белән, әлеге карар нигезендә хезмәт өчен түләү шартларына күчкән вакытка гамәлдә булган хезмәт өчен түләү системасы нигезендә түләнә торган хезмәт хакыннан кимрәк була алмый, дип билгеләргә.

6. Балтач муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары җитәкчеләренә, хезмәткәрләрнең тиешле профсоюз органы белән килештереп:

Балтач муниципаль районы яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә хезмәт өчен түләүнең шартларын билгели торган коллектив шартнамәләргә, килешүләргә, локаль норматив хокукый актларга тиешле үзгәрешләр кертергә;

Балтач муниципаль районының яшьләр сәясәте муниципаль оешмалары хезмәткәрләренә төп хезмәт шартлары үзгәрү турында хәбәр итәргә.

7. Әлеге карарның 2026 елның 1 гыйнвареннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә карата гамәлдә булуын билгеләргә.

8. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Балтач муниципаль районының рәсми сайтында (http://baltasi.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә.

9. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны Татарстан Республикасы Балтач район башкарма комитеты җитәкчесенең беренче урынбасарына йөкләргә.

Татарстан Республикасы
Балтач район башкарма комитеты
җитәкчесе А.Ф.Хәйретдинов